ГЛАВА МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН», МЭР ГОРОДА ЛЕНИНОГОРСКА

«ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШЛЫГЫ ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ МӘРЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **К А Р А Р**

14.04.2026 г.Лениногорск № 28

Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгы, Лениногорск шәһәре мэрының 2016 елның 23 декабрендәге 161 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә түләүсез юридик ярдәм турында» Федераль законның 20 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 1 апрелендәге 48-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә түләүсез юридик ярдәм турында «Федераль законның 20 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2026 елның 23 мартындагы 64-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгы, Лениногорск шәһәре мэрының 2016 елның 23 декабрендәге 161 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү тәртибенә түбәндәге үзгәреш кертергә:

3.1 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 3.1.11.1 һәм 3.1.11.2 пунктлары белән тулыландырырга:

«3.1.11.1) белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада көндезге бүлектә белем алу шарты белән өлкән баласы унсигез яшькә яки егерме өч яшькә җиткәнче өч һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы ата-аналар;

3.1.11.2) социаль ярдәм чаралары күрсәтүгә, аларны мәҗбүри күченүчеләр, качаклар дип тануга, Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча сыену урыны алуга, Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча сыену урыны алуга яки Россия Федерациясе гражданлыгына кабул итүгә бәйле мәсьәләләр буенча түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итсәләр, аларны мәҗбүри күченүчеләр, качаклар дип тануны сорап мөрәҗәгать итүче затлар;».

2. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башлыгы, Лениногорск шәһәре мэрының 2016 елның 23 декабрендәге 161 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 16 апрелендәге 31 номерлы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башлыгы, Лениногорск шәһәре мэры карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында веб-адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Лениногорск муниципаль районы»муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

М.Н. Гирфанов

Хәйбрахманов И.Р.
5-44-72